ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

2023 ел йомгаклары буенча «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында

2023 ел йомгаклары буенча «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире Г.И. Сабированың һәм «Республика Татарстан» газетасы баш мөхәррире А.Е. Угаровның мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 ел йомгаклары буенча «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында мәгълүматларны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон версияләре өчен яңа заманча платформалар булдыру һәм аларга ярдәм итү эшләрен өстәмә финанслау мөмкинлеген карарга тәкъдим итәргә.

3. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары баш мөхәррирләренә:

3.1. Басма һәм электрон рәвештәге газеталар чыгаруны, газеталар таратуны, басылып чыккан материалның 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан расланган дәүләт йөкләмәләре нигезендә билгеләнгән тематикага туры килүен тәэмин итүне дәвам итәргә.

3.2. Заманча эшчәнлек рәвешләрен гамәлгә кертү, публикацияләрнең аналитик эчтәлеген көчәйтү, Татарстан Республикасының сәяси, иҗтимагый, икътисадый һәм мәдәни тормышы турында мәгълүмати һәм башка

материаллар әзерләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары вәкилләрен җәлеп итү эшен дәвам итәргә.

4. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләренә аларның уставларында билгеләнгән максатларны һәм бурычларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә.

4.2. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре белән берлектә язылу кампанияләре нәтиҗәләрен анализларга, тиражны һәм язылучылар санын арттыру чараларын күрергә.

4.3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм Федераль почта хезмәтенең «Татарстан почтасы» идарәсе белән берлектә Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе объектлары челтәрен, вакытлы басмаларны үз вакытында китерү хезмәтләрен камилләштерү чараларын күрергә.

5. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарын гамәлгә куючылар советларына «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренең дәүләт йөкләмәләрен үтәвен тикшереп торуны һәм, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан фикер алышуга «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары редакцияләре эшчәнлеген камилләштерү һәм аларның эш нәтиҗәлелеген арттыру тәкъдимнәрен кертүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 феврале
№ 2324-VI ДС